РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ СТАРОИКШУРМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422066, Республика Татарстан, Сабинский район, с.Старая Икшурма, ул. Ленина, д.17
тел. 8(84362) 41-6-47

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ИКШЕРМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

422066, Татарстан Республикасы, Саба районы, Иске Икшермә авылы, Ленин урамы, 17 йорт
тел.8(84362) 41-6-47

e-mail: sik.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
24.09.2018 г.

КАРАР
№ 25

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю һәм аны куллану буенча җирле референдум билгеләү турында

“Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре турында” 12.06.2002 №67-ФЗ Федераль законның 15 нче статьясына, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның төп принциплары турында” 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 22.56 статьялары, Татарстан Республикасының “Җирле референдум турында” 24.03.2004 №23-ЗРТ 18 статьясы, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясына туры китереп, Иске Икшермә авыл җирлеге Советының 21.09.2018 № 24 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары, Иске Икшермә авыл җирлеге башкарма комитетының 21.09.2018 № 50 “Референдум уздыру инициативасы турында” карары нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлеге КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Иске Икшермә авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасы җыю соравын кертү буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга куеласы сорауларны түбәндәгечә расларга:

“Сез яшәү урыны буенча Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Иске Икшермә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 2019 елда 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм аны түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлтү белән ризамы:

- Иске Икшермә авылында күмү урыннарын карап тору;
- Татар Икшермәсе авылында уен мәйданчыгын булдыру;
- Өч Нарат авылында уен мәйданчыгын булдыру;

ӘЙЕ ЮК”

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында бастырырга.

4. Карар басылып чыккан (халыкка хәбәр ителгән) көннән соң үз көченә керә.

Иске Икшермә авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Нурмухаметов